

Авыл  хезмәтчәннәре миндә аеруча горурлык һәм хормәт уята. Аларнын югары кvрсәткечләренә нинди тырышлык белән ирешелvен кvз алдына китерv авыр.  Һәр унышлы хужалык артында бердәм коллектив һәм грамоталы житәкче тора.
Рузаевка  районы «Стрелецк» хужалыгы директоры Ринат Юнир улы Арюков унышлы житәкчеләрнен берсе. Узган елны хужалык югары нәтижәләр белән тәмамлый -  ашлык жыю һәм сот житештерv буенча кvрсәткечләре житди vскән.

Алты мен ике йоз жирдә бертеклеләрдән козге белән язгы бодай, арпа,  кукуруза, житен (лён) житештерсәләр, мал-туар очен кvпьеллык vләннәр дә  vстерәләр. Быел да шул ук vсемлекләрне житештерергә жыеналар. Мона анын  белеме дә ярдәм итә, чонки белгечлеге буенча ул Н.П.Огарев исемендәге  университетнын агрономия бvлеген тәмамланган. Тагы әйтеп китәргә кирәк,  Мордовиядә эре инвестицион проектлар гамәлгә ашырыла: алар да эштә зур  ярдәм чыганагы, бигрәк тә корылык һәм башка табигый аномалияләр  булганда.
Ата-бабаларыбыз гомер-гомергә, буыннан-буынга һәрвакыт зур  унышларга, зур терлекчелек продукциясенә омет баглап яшәде. Әйтергә  кирәк, хәзерге уллары-кызлары, аларнын нинди хезмәт куйганнарын истә  тотып, ризыкнын ничек итеп остәлгә килеп эләккәнен кvреп vскән,  тормышнын ботен авырлыклары белән очрашкан буынга рәхмәт йозеннән шундый  мул уныш очен тырыша язма героебыз. «Стрелецк» хужалыгында барлыгы эре  могезлеләр 3200 баштан 1200 савым сыерны унике сыер савучы сменалап  сава. Бер сыердан алты мен литр сот саву рубежын атлаганнар. Сыер савучылар лаеклы эш хакы алып хезмәт итә. Ирешкән унышлары очен  премияләр каралган. Коллектив килешvе буенча да унай шартлар тудырылган.  Бу шартлар «Стрелецк» хужалыгынын башка хезмәткәрләренә дә кагыла.  Әйтеп китәргә кирәк, бу хужалыкта 180 кешегә эш урыны булдырылган – авыл  очен бу бик тә матур кvрсәткеч. Хезмәтчәннәрнен 30 процентын 25-45  яшьлекләр тәшкил итә. Торак кирәк булганнарына, ипотека тvләv очен,  процентсыз ссуда бирә хужалык һәм хезмәткәрнен эш хакыннан ай саен  тотылып барыла. Менә тәжрибә, омтылыш һәм эш союченлек нәрсәне анлата.
Сонгы  елларда авылларда халык конкvрешен арттыруга, территорияләрне ямьләндерvгә, заманча социаль инфраструктура булдыруга зур игътибар  бирелә: бирeдә дә, торле программаларга кереп, хужалык керткән олеше  бар. Ринат Юнир улы Стрелецко-Слободское авылын беркайчан да игътибарсыз  калдырмый; анын проблемаларын хәл итәргә ярдәм итә. Депутат буларак  кышларын авылга да, Рузаевка шәһәренә дә юлларны жыештыру һәм карны  чыгару очен техника жибәрә. Бу - авыл һәм район очен бик кыйммәт.
Хужалык  ярдәмен махсус хәрби операциядә катнашучыларнын гаиләләре һәм барлык

сугышчылары сизә. Аларга даими рәвештә гуманитар ярдәм кvрсәтелә. Бvгенге кон очен бу эшләр бик тә кирәкле һәм актуаль. Аралашу һәм социаль жаваплылык очен аерым Рәхмәтен, Ринат Юнир улы Арюковнын Юбилее унаеннан, Рузаевка районы житәкчесе Александр Борисович Юткин белдерде. Тырыш хезмәт макталырга тиеш. Зур нәтижәләргә ирешvе очен «Почетный работник агропромышленного комплекса России», Мордовия Главасы премиясе лауреаты һәм башка олы бvләкләр иясе ул. Бер жомлә белән әйткәндә безнен халык - авылнын топ хәзинәсе, ә авыл хужалыгы - икътисадыбызнын топ тармагы.
Татарларда бер матур әйтем бар: язын - чана, кышын - арба әзерлә. Шуна дәлил итеп, «Стрелецк» хужалыгы директоры Ринат Юнир улы Арюков яз башы эшләрен башлап жибәргән инде. Кыш буе торле тор машиналарны ремонтлаган булса, язнын беренче коненнән ук орлык запасларын тикшереп чыккан. Әмма озимойлар нинди хәлдә икән дип борчылып тора.
Ринат Юнир улынын гаиләсе дә бик матур. Гаиләсе – анын ныклы терәге, бәхете. Хатыны Галия Рякип кызы белән бергәләп, бер кыз, бер малай тәрбияләп vстерәләр. Кызлары Диляра дизайнер булып Казанда хезмәт итә, магистратурасын да Казанда тәмамлый. Амирлары мәктәптә укый; 6 нчы сыйныфта булса да, олимпиадаларда катнаша.
Эштә дә, ойдә дә тәртип.

**Наилә НАСЫРОВА**